ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ БОГАДЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕСОВЕТЫ

423763, Иске Богадыа вылы, Үзәк ур., 60нчыйорт.
Тел.:(85552)5-45-30; факс:5-45-30;
E-mail: sbuq-akt@yandex.ru

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ СТАРОБУГАДИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

423763, село Старые Бугады,
ул. Центральная, дом 60.
Тел.:(85552)5-45-30; факс:5-45-30;
E-mail: sbuq-akt@yandex.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«24» ноябрь 2020 ел** **№ 11**

## Иске Богады авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Иске Богады авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы, Иске Богады авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ :

1. Иске Богады авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, һәр балигъ булган яшәүчедән, көндезге формада белем алучы студентлардан кала, 1 төркем инвалидлардан кала, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан кала, 2021 елда үзара салымның бер тапкыр 500(Биш йөз) сум түләвен кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

* Ритуаль хезмәт күрсәтүне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:
- җирләү урыннарын документаль рәсмиләштерү;
- зират коймасын ремонтлау;
- ритуаль хезмәтләр өчен инвентарь алу;
*.Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
- җирлек торак пунктларында хуҗасыз объектларны сүтү, хуҗасыз территорияләрне ремонтлау һәм коймалар кую.;
- авыл җирлеге территориясендә агач кисү;
- торак пунктлардагы урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләрне әзерләү һәм урнаштыру;
* Массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:
- авыл җирлегендә яшәүчеләрнең массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру, аларны төзекләндерү, коймалар белән тәэмин итү;
*. Автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- юлларны ремонтлау һәм карап тоту (ПГС салу, грейдерлау, кардан чистарту);
* Җирлек чикләрендә Халыкны электр белән тәэмин итү һәм су белән тәэмин итү:
- урамнарны яктырту электр челтәрләрен карап тоту;
- су челтәрләрен һәм чишмәләрне ремонтлау, карап тоту, су чыганакларын лицензияләү, документаль рәсмиләштерү.

2. Актаныш муниципаль районы Иске Богады  авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында  гражданнар җыены  нәтиҗәләрен игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында " Иске Богады авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Авыл җирлеге башлыгы И.Ф.Фаттахов.